**Республика Татарстан**
**Исполнительный комитет**
**Пестречинского**
**муниципального района**
422770, с. Пестрецы, ул. Советская, 18

**Татарстан Республикасы**
**Питрәч муниципаль**
**районы**
**башкарма комитеты**
422770, Питрәч авылы, Совет урамы, 18

тел. +7 (84367) 3-02-02 факс: (84367) 3-02-01 E-mail: pitriash@tatar.ru

# ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

20 сентябрь, 2018 ел. № 1527

«2018-2019 елларга Питрәч муниципаль районы балалары һәм яшьләре» район максатчан программасын раслау турында Питрәч муниципаль районы башкарма комитетының 2018 елның 08 маендагы 714 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 08 маендагы "Питрәч муниципаль районы балалары һәм яшьләре" район максатчан программасын раслау турындагы карарын туры китерү максатында. «Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына бюджет процессын камилләштерүгә бәйле үзгәрешләр кертү турында» 07.05.2013 № 104-ФЗ номерлы Федераль закон белән Питрәч муниципаль районы башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 08 маендагы "2018-2019 елларга Питрәч муниципаль районы балалары һәм яшьләре" район максатчан программасын раслау турында карары белән расланган Кушымтаның исемендә һәм текстында, 2018 елның 8 маендагы кушымталар белән Программаның исемендә һәм текстында. №714 тиешле килешләрдә «максатчан» сүзен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://www.pestreci.tatarstan.ru һәм «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда http://pravo.tatarstan.ru урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Питрәч муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары З.Ш. Мөхәммәтгәрәевага йөкләргә.

Муниципаль район Башкарма комитет җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы А.В. Хәбибуллин